# КАРАР

**27 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 27 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә җиткән 3 яки аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр һәм ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Өлге авылының урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү;
- Өлге авылында урамнарга энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кәчимер авылы территориясен төзекләндерү (яшелләндерү, агачларны кисү);
- насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Өлге авылының Үзәк урамын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өлге авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү;
- Өлге авылының балалар мәйданчыгын коймалау, проект-смета документларын эшләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 304 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 162 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 162 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә җиткән 3 яки аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр һәм ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Өлге авылының урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү;

- Өлге авылында урамнарга энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Кәчимер авылы территориясен төзекләндерү (яшелләндерү, агачларны кисү);

- насослар сатып алу һәм урнаштыру;

- Өлге авылының Үзәк урамын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Өлге авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү;

- Өлге авылының балалар мәйданчыгын коймалау, проект-смета документларын эшләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Манзарас
авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина